Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча гавами тыңлаулар башлану турында ХӘБӘР ИТҮ

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында шушы мәгълүмат белән хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1) Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы.
2) Шәһәр төзелеше регламентлары.

Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе һәм сроклары:

Ачык тыңлаулар 16.10.2025 елдан 13.11.2025 елга кадәр үткәрелә һәм түбәндәге этапларны үз эченә ала:

- гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;

гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектны урнаштыру, аның рәсми сайтында һәм экспозицияләрен ачу;

-проект экспозициясен үткәрү;

- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:

- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;

-Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;

-күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә Иске Шөгер һәм Яңа Шөгер авылларында үткәрелә.

2025 елның 24 октябреннән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер авыл җирлегендә ачык тыңлауларда каралырга тиешле җирләрдән файдалану һәм Иске Шөгер авыл җирлегенең төзелеш кагыйдәләре проекты экспозициясен түбәндәге адреслар буенча авыл җирлеге администрациясе бинасында ачарга: - Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Иске Шөгер авылы, Совет урамы, 1нче йорт;
- Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Яңа Шөгер авылы, Гагарин ур.1а й.

Проект экспозициясен үткәрү сроклары: 24.10.2025 дан 10.11.2025 га кадәр

Проект экспозициясе белән танышу вакыты – 9.00 дән 11.00 гә кадәр һәм 14.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр дүшәмбедән җомгага кадәр.

Гавами тыңлауларда катнашучыларга җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына кагылышлы үз тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен язма рәвештә, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Иске Шөгер авылы, Совет урамы, 1 нче йорт яисә Sshug.Len@tatar.ru, яисә проект экспозицияләренә керүчеләрне исәпкә алу журналында язма рәвештә яисә телдән формада кертергә тәкъдим итәргә.

Язма рәвештә тәкъдим ителгән искәрмәләргә һәм тәкъдимнәргә документларның күчермәләре дә кушып бирелергә тиеш: физик затлар өчен яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга куелган һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» 2014 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләр нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү турында документның күчермәсе; юридик затлар өчен - ЕГРЮЛдан өземтә.

Экспозиция эше барышында «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына экспозициягә килүчеләргә консультация бирүне оештырырга.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын билгеләргә:

10 ноябрь, 2025 ел 17.30 сәг.: Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Иске Шөгер авылы, Совет ур., 1.

10 ноябрь, 2025 ел 17.30 сәг.: Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Яңа Шөгер авылы, Гагарин ур., 1а.

2025 елның 16 октябренә кадәр җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын рәсми сайтта түбәндәге адрес буенча: https://leninogorsk.tatarstan.ru/ «Авыл җирлекләре»бүлегендә урнаштырырга.

Әлеге хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

- Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Иске Шөгер авылы, Совет ур.1й;

- Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Яңа Шөгер авылы, Гагарин ур.1а й.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге» башлыгы Л.М.Шиһапова